Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районының
Арча шәһәр муниципаль берәмлеге
Арча шәһәр Советы
422000, Арча ш. Совет мәйданы, 27
тел. 3-16-25, 3-12-35

Муниципальное образование
город Арск
Арского муниципального района
Республики Татарстан
Совет города Арск
422000,г. Арск, площадь Советская , 27
тел. 3-16-25, 3-12-35

**Арча шәһәр Советы**
**КАРАРЫ**

**№ 124** **“21 " август 2019 ел**

**Арча шәһәр Советының 2017 елның 27 октябрендәге 74 номерлы номерлы «Җир салымы турында» карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Салым кодексының икенче өлешендәге 31 бүлек, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы “Арча шәһәре” Уставы нигезендә Арча шәһәр Советы КАРАР бирде:

1. Арча шәһәр Советының «Җир салымы турында» 2017 елның 27 октябрендәге 74 номерлы карарына түбәндәге үзгәреш кертергә:

-2 нче пунктның 5 пунктчасын түбәндәге редакциядә бирергә:

«Эшмәкәрлек эшчәнлегендә кулланылмый торган шәхси ярдәмче хуҗалык, бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару өчен алынган (бирелгән) җир кишәрлекләренә, шулай ук 2017 елның 29 июлендәге «Гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 217-ФЗ номерлы Федераль законда каралган гомуми кулланылыштагы җир кишәрлекләренә карата 0,18 процент.”

2. Әлеге карар Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Арча муниципаль районының Интернет мәгълүмати- телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында рәсми басылып чыккан көннән бер айдан соң үз көченә керә.

“Арча шәһәре” муниципаль берәмлеге башлыгы,
Арча шәһәр Советы рәисе И. Г. Нуриев